ГЛАВА
МЕНЗЕЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНЗӘЛӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

21.10.2015 ел г. Мензелинск № 71

Минзәлә муниципаль районында «Татнефть» ААҖ аша «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын һәм авыл хтерриториясен үстерү» дәүләт йпрограммасы буенча авыл хуҗалыгы азык җыю техникасын бүлү турындагы нигезләмәне раслау хакында

2015-2016 елларга муниципаль район агросәнәгать комплексының матди-техник базасын яңарту һәм энергия нәтиҗәлелеген арттыру максатларында

КАРАР ЧЫГАРАМ:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районында «Татнефть» ААҖ аша «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын һәм авыл территорияләрен үстерү» дәүләт программасы буенча авыл хуҗалыгы азык җыю техникасын бүлү турында Нигезләмәне расларга (1 нче кушымта).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе И.Т. Шагалиевка йөкләргә

Совет рәисе А.Ф. Сәлахов

Татарстан Республикасы
Минзәлә муниципаль районы
башлыгының карарына
1 нче кушымта
21.10.2015ел №71

# НИГЕЗЛӘМӘ

Минзәлә муниципаль районында «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын һәм авыл территорияләрен үстерү» дәүләт программасы буенча «Татнефть» ААҖнең авыл хуҗалыгы азык җыю техникасын бүлү турында

Әлеге нигезләмә «Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексын һәм авыл территорияләрен үстерү» программасы буенча «Татнефть»ААҖ аша 2015-2016 елларда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләренә бушлай азык җыю техникасын бүлеп бирүне регламентлый.

Авыл хуҗалыгы азык җыю техникасы бүлеп бирелгәндә, авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә түбәндәгеләр исәпкә алына:

- авыл хуҗалыгы азык җыю техникасын алучылар булып Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы территориясендә яшәүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре санала;

- авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүчеләрендә авыл хуҗалыгы хайваннары булу, чөнки бүлеп бирелгән авыл хуҗалыгы техникасы азык җыю техникасы булып тора;

-авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренең авыл хуҗалыгы азык җыю техникасына ихтыяҗы;

Әлеге программа буенча ел саен муниципаль районга, нигездә, 5 берәмлек авыл хуҗалыгы азык җыю техникасы, крестьян (фермер) хуҗалыкларына, бәяләренә бәйсез рәвештә, елга кимендә бер авыл хуҗалыгы азык җыю техникасын аерып күрсәтергә мөмкинлек бирүләрен исәпкә алып.